КИЛЕШЕНГӘН:
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы җитәкчесе,баш мөхәррир вазыйфаларын башкаручы
________ Р.А.Гасыймова
«_10_» сентябрь 2020 ел

КИЛЕШЕНГӘН:
балалар белән эш буенча директор урынбасары
________ Р. Н. Каюмова
«_10_» сентябрь 2020 ел

РАСЛЫЙ:
«ҮКС» МБУ директоры
________ В.М. Гайнуллина
«_10_» сентябрь 2020 ел

# «Шигъри тәлгәшләр» төбәкара бәйгесенең НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1 Бу нигезләмә «Шигъри тәлгәшләр» (алга таба – Бәйге) төбәкара бәйгесен оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2 Бәйгенең оештыручылары «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «Көмеш кыңгырау» республика балалар һәм яшүсмерләр газетасы.

## 2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары

2.1 Бәйгенең төп максаты – әдәби иҗатка сәләте булган балаларны һәм яшүсмерләрне барлау, таныту һәм сәләтләрен үстерү.

2.2 Бәйгенең бурычлары:

- яшь буында татар теленә, татар әдәбиятына кызыксыну уяту;
- китапханәгә китап укучыларны тарту һәм татар китабының дәрәҗәсен үстерү;
- шигъриятькә карата уңай эмоциональ мөнәсәбәт тәрбияләү.

## 3. Бәйгедә катнашучылар

3.1 Бәйгедә 5- 15 яшьтәге теләге булган һәркем катнаша ала.

3.2 Бәйге түбәндәге яшь төркемнәрендә үткәрелә:

- 5-6 яшьтәге балалар;
- 7-8 яшьтәге балалар;
- 9-11 яшьтәге балалар;
- 12-15 яшьтәге балалар.

3.3 Бәйгедә катнашу шәхси һәм ирекле.

## 4. Бәйгенең шартлары һәм үткәрү тәртипләре

4.1 Бәйге түбәндәге номинацияләр буенча уздырыла:

- « Китап алсаң кулыңа, нур сибелер юлыңа» (китап, китапханә турында шигырь язу);
- «Көмеш кыңгыраулы балачак мәңге күңелләрдә калачак» (мәктәп, укытучы, «Көмеш кыңгырау» газетасы турында шигырь язу);
- «Туган телем - назлы гөлем» (татар теле турында шигырь язу).

4.2 Бәйгедә катнашу бәясе - 200 сум. Взнос теләсә кайсы банк бүлекчәләрендә түләнә ала. Түләү гариза биргәннән соң башкарыла (Кушымта 1). Түләү өчен реквизитлар (Кушымта 2).

4.3 Бәйгедә катнашу Бәйге шартлары белән килешүне аңлата.

## 5. Бәйгене уздыру срогы һәм этаплары

5.1 Бәйге 2020 елның 14 сентябреннән 2020 елның 31 октябренә кадәр 3 этапта уздырыла.

1 нче этап: 14.09.2020–24.10.2020 – эшләрне кабул итү;
2 нче этап: 26.10.2020 -28.10.2020– нәтиҗәләр ясау;
3 нче этап 29.10.2020 - 31.10.2020– Дипломнар җибәрү.

### 6. Бәйгегә җибәрелүче эшләргә таләпләр

6.1 Бәйгедә катнашучылар үзләре язган шигырьләрне, гаризаларын, квитанцияләрен 14 сентябрьдән 24нче октябрьгә кадәр 12нче санлы китапханәнең электрон почтасына җибәрә.

6.2 Бәйгедә катнашу өчен «Бәйге номинацияләре»нә туры килгән шәхси эшләр кабул ителә.

6.3 Шигырь татар телендә булырга тиеш.

6.4 Бәйгегә тәкъдим ителә торган шигырь Word документы форматында 2 куплеттан аз булмаска, 5 куплеттан (шрифт үлчәме – 14; ара интервалы - 1,5;) артмаска тиеш.

6.5 Бәйгедә катнашучыдан бер генә эш кабул ителә.

6.6 Нигезләмәнең шартларына туры килмәгән эшләр бәйгедә катнашмый һәм каралмый.

### 7. Эшләрне бәяләү критерийлары

7.1 Бәйге эшләрен бәяләү 5 баллы система буенча уздырыла. Йомгаклау нәтиҗәсе балларны кушу юлы белән ирешелә.

7.2 Бәйге эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

- күрсәтелгән темага туры килү;
- оригинальлек һәм мөстәкыйльлек;
- эшне башкаруга иҗади якын килү.

### 8. Жюри әгъзалары:

8.1 Эшләрне бәяләүне Бәйгенең жюри әгъзалары гамәлгә ашыра.

8.2 Бәйгене жюри рәисе җитәкли.

8.3 Жюриның барлык карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

8.4 Эшләр карау вакытында жюри өстәмә номинацияләр тәкъдим итә ала.

### 9. Бәйгегә йомгак ясау һәм бүләкләү

9.1 Бәйгедә җиңүчеләрне жюри билгели. Жюри карары ахыргы булып тора һәм яңадан каралмый.

9.2 Җиңүчеләр һәр яшь төркемендә һәм номинациядә 1, 2, 3 урыннар өчен Дипломнар белән һәм «Көмеш кыңгырау» газетасына бушлай яздыру белән бүләкләнә. Җиңүчеләр исемлегенә кермәгән катнашучылар «Катнашкан өчен» Дипломнары алачак. Дипломнар электрон рәвештә гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелә.

### 10. Бәйгене рекламалау

10.1 Бәйге массакүләм мәгълүмат чараларында https://библиотека-челны.рф официаль сайтында һәм «12нче санлы китапханә» ВКонтакте төркеме битендә (https://vk.com/club137987058), «Көмеш кыңгырау» газетасының сайтында (http://chelny-rt.ru/) яктыртылачак.

### 11. Бәйгене уздыру урыны һәм элемтәләр өчен телефон:

Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 12нче санлы филиалы: Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманов урамы, 48нче йорт (Яңа шәһәр, 14/01). Телефон: 35-33-86; e-mail: cbs_filial12@mail.ru

Җаваплы: Шәкүрова З. М.

**Кушымта 1**

**Гариза**

(«Шигъри тәлгәшләр» төбәкара бәйгесенең теркәлү карточкасы)

Катнашучының фамилиясе, исеме ____________________________________________

Катнашучының яше (тулы яше) _____________________________________________

Катнашучының укыган мәктәбе______________________________________________

Шигырьнең исеме _________________________________________________________

Бәйгедә катнашучының телефоны, электрон адресы (телефон, e-mail) ______________

Җитәкчесенең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме (телефон, e-mail)

_____________________________________________________________________________

Бәйге шартлары белән таныштым һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза:

Дата ______________________ Имза____________

**Кушымта 2**

**Реквизиты для перечисления организационного взноса:**

| | |
|---|---|
| Адрес | 423807, г. Набережные Челны, б-р Ямашева, д.4/14 А |
| ИНН/КПП | 1650105517 / 165001001 |
| Расч. счет | 40701810692053000045 |
| Корр.счет | 30101810000000000805 |
| БИК | 049205001 |
| Банк | Отделение – НБ Республика Татарстан |
| Лицевой счет | ЛБВ 30800866 |
| ОКТМО | 92730000 |
| КБК | 00000000000000000131 |
| Назначение платежа | Библиотека-филиал №12, Фамилия и имя участника, конкурс «Шигъри тәлгәшләр» |